ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, 5, с.Бишня,
Зеленодольский район, 422528

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИШНЭ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Центральная ур., 5, Бишнэ ав,
Зеленодольск районы., 422528

# БОЕРЫК

2022 елның 31 гыйнвары №2

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм җирләү эше турында»гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында»гы 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә Бишнә авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1. Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә 6964,68 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Бишнә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 2021 елнын 01 февралендагы 3 нче карары 2022 елнын 1 февраленнэн үз көчен югалткан дип санарга.
3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4.Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

**Бишнә авыл**
**жирлеге башлыгы** **И.М.Фатхуллин**

Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы №2 карарына 1 нче кушымта

ТР Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегендә 2022 елнын 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3795,41 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка ташу | 1081,18 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2088,09 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |

Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге башкарма комитетының 20221 елның 31 гыйварындагы №2 карарына 2 нче кушымта

ТР Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегендә 2021 елнын 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне төрү | 670,55 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3124,86 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка ташу | 1081,18 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 2088,09 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |